Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Шомырбаш авыл җирлеге Советы

**КАРАР № 4**

Шомырбаш авылы 7 декабрь, 2021 ел

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Шомырбаш авыл җирлеге Советының 2014 елның 9 октябрендәге “Җир салымы турында”гы 9 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Муниципаль норматив хокукый актны гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында, 2021 елның 7 июлендәге “Россия Федерациясе Салым кодексының беренче һәм икенче өлешенә һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында” 305-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының “Шомырбаш авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Күки авыл җирлеге Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Шомырбаш авыл җирлеге Советының 2014 елның 09 октябрендәге “Җир салымы турында”гы 09 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3 пунктның 2 абзацында “, шулай ук күрсәтелгән объектларны урнаштыру өчен аталган җир кишәрлекләре” сүзләрен өстәргә.

2. Әлеге карар рәсми игълан ителгән (халыкка җиткерелгән) көненнән үз көченә керә һәм 2021 елның салым чорындагы җир салымын исәпләүгә бәйле хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

3. Карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Шомырбаш авыл җирлеге территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендларында: Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе районы, Шомырбаш авылы, Совет урамы, 47 йорт; Таулар авылы, Ленин урамы, 50А йорт; Алан-Полян авылы, Я.Емельянов урамы, 6 йорт; Кызыл Йолдыз урман хуҗалыгы авылы, Парк урамы, 10 йорт , Балык Бистәсе муниципаль районының рәсми сайтында интернет-телекоммуникация челтәрендә веб-адрес буенча урнаштырылган: http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru урнаштырырга.

4. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне үземнең җаваплылыкта калдырам.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Шомырбаш авыл җирлеге Башлыгы И.Н.Сафин